

Ромоданово районында элек-электән күпләп татарлар яши, шул исәптән борын-борыннан үзенен белемле авыл (Шәриф Камал да Ләбәжә мәдрәсәсендә укыган) дип билгеле булган Ләбәжә - Алтар авылы. Бүген без Алтар топ мәктәбе укучылары турында искә алырбыз. Алар татарлыгыбызны, милли рухны, телне, гореф-гадәтләребез, тарихыбызны сак-лыйлар.      Әле генә мәктәпнен Беренче хәрәкәт активистлары булган 9 класс укучысы Алина Халикова; 8 класс укучылары – Риана Яфарова, Гелназ Юнусова; алтынчы класс укучылары - Аделина Сайфетдинова, Малика Исхакова һәм 4 класста укучы Самира Сайфетдинова «Талантлар йолдызлыгы» («Созвездие талантов») республика конкурсында шатланып катнаштылар. Осталыкларын һәм креативлыкларын күрсәткән сәләтле катнашучыларны житәкләп унышларга ирешергә ярдәм итүче Алтар топ мәктәбенен музыка укытучысы Лариса Камиль кызы Баляева.
Югарыда санап киткән кызлар туган татар телләрен бик тә яраталар. Алар татар халык биюләрен жиренә житкереп бииләр, мәктәп һәм авыл клубы коллективларында жырлар да жырлыйлар, сәнгатьле иттереп саф әдәби телендә шигырьләр дә яттан сәнгатьле сойлиләр. Барысына да татарлыкны югалтмыйча, тарихыбызны, әдәбиятыбызны, мәдәниятыбызны белергә, яратырга ойрәтүдә татар теле һәм әдәбияты буенча белем биргән мәктәп директоры урынбасары Венера Галлям кызы Конешеванын роле зур. Укучылары белән горурланып болай дип сойләде:
- Кызларыбыз бар жирдә алдынгылар. Алина Халикова, Риана Яфарова, Гелназ Юнусова, Аделина Сайфетдинова, Малика Исхакова, Самира Сайфетдинова мәктәптә ойрәнелгән предметларны әйбәп үзләштереп яхшы укучылар арасындалар. Мисалга Риана Яфарованы алыйк. Ул һәрбер чарада йә жинүче, йә призер. Искиткеч талантлы кыз Риана Яфарова - Ромоданово районы Алтары авылынын горурлыгы. Риана мәктәпнен активисты: «5»ле билгеләренә генә укый. Барысына да олгерә. Жаваплы һәм игътибарлы, белемле, ижади фикер йортүгә ия. Район һәм мәктәп этап ларын исәпкә алмаганда, республика этабынын барлык зур конкурсларында һәм чараларында һәрвакыт катнаша: - «Тере классика» (мәктәп һәм муниципаль этапларда жинүче һәм призер) – «Созвездие талантов», «Шумбрат, Мордовия»,


ДИПЛОМ